**«Блогер.Татар»**

**III республикакүләм блогерлар бәйгесе буенча**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Нигезләмә Гаилә темасына багышланган III республикакүләм блогерлар бәйгесен оештыру һәм үткәрү тәртибен, анда катнашу шартларын билгели.

1.2. Конкурс Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) ярдәме белән уздырыла.

1.3. Бәйгене оештыручы – «Матбугат.ру» порталы (алга таба – Оештыручы).

**2. Бәйгенең максатлары һәм бурычлары**

2.1. Бәйге социаль челтәрләр кулланучылары арасында татар телен популярлаштыру максатында оештырыла.

2.2. Бәйгенең бурычлары:

- Интернетта һәм социаль челтәрләрдә татар телен куллану даирәсен арттыру

- виртуаль аралашуда татар язма телен һәм сөйләм телен камилләштерү

**3. Бәйгедә катнашу шартлары**

3.1. Бәйгедә социаль челтәрләрдә татар телендә гаилә темасын яктырткан контент авторлары катнаша.

3.2. Бәйгедә катнашуда яшь ягыннан һәм территориаль яктан чикләүләр юк.

3.3. Бәйгедә катнашуда блогка язылучылар саны буенча чикләүләр юк.

3.4. Бәйгедә төрле социаль челтәрләрдәге блоглар катнаша ала («Инстаграм», «Ютуб», «Вконтакте», «Фейсбук», «Одноклассники» һ.б.)

3.5. Бәйгедә катнаша алмый:

- коммерциягә нигезләнгән аккаунтлар (челтәрле маркетинг, интернет-кибет һ.б.);

- ботлар.

3.6. Эшләрне бәяләү критерийлары:

- эшнең бәйге нигезләмәсенең барлык шартларына туры килүе;

- татар теленең камиллеге;

- контентның кызыклы, файдалы, оригиналь, сыйфатлы булуы;

- аудиториянең активлыгы (язылучылар саны, лайклар, репостлар, комментарийлар һ.б.)

- техник башкарылыш (дизайн, бизәлеш, монтаж һ.б.)

**4. Эшләрне бәйгегә җибәрү тәртибе:**

4.1. Эшләр **bloger.tatar@mail.ru** электрон почтасына кабул ителә.

4.2. Эшләрне тапшырганда күрсәтергә тиешле мәгълүмат:

- катнашучының исеме, фамилиясе, атасының исеме;

- катнашучының телефон номеры;

- постка сылтама;

- кыскача мәгълүмат (мәҗбүри түгел).

4.3. Бәйгедә катнашырга теләүченең bloger.tatar@mail.ru электрон адресына хат җибәрүе әлеге Нигезләмә белән тулысынча килешүен һәм «Шәхси мәгълүматлар турында»гы Федераль канун (Федеральный закон от 27.07.2006 №152-ФЗ «О персональных данных») нигезендә шәхси мәгълүматларын кулланырга рөхсәт бирүен раслый.

4.4. Блогерның бәйгедә катнашуы факты – конфиденциаль мәгълүмат түгел һәм бәйгенең рәсми сайтында, массакүләм мәгълүмат чараларында күрсәтелергә мөмкин.

**5. Жюри**

5.1. Комиссия тарафыннан 5 кешедән торган жюри төзелә. Жюри составына рәис һәм жюри әгъзалары керә.

5.2. Җибәрелгән эшләрне бәйгедә катнашуга кабул итү-итмәүне жюри мөстәкыйль рәвештә хәл итә.

5.3. Жюри утырышында кимендә 3 әгъза катнашса, кворум санала.

5.4. Жюри карарлары коллегиаль кабул ителә. Тавышлар бирү саннары тигез булганда, жюри рәисенең тавышы хәлиткеч санала.

**6. Җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү**

6.1. Бәйгедә 10 җиңүче билгеләнә.

6.2. Бәйге ике номинациядә үткәрелә:

- «Гаилә темасына иң яхшы контент» (блогерлар арасында 5 җиңүче)

- «Гаилә темасына иң яхшы контент» (шәхси аккаунтлар арасында 5 җиңүче)

6.3. Бер үк кеше ике номинациядә дә җиңә алмый. Катнашучыларны номинацияләргә бүленешен жюри хәл итә.

6.4. Бер катнашучыдан иң күбе 3 эш кабул ителә.

6.5. Һәр җиңүчегә 20 0000 сум күләмендә акчалата премия тапшырыла.

**7. Бәйгене үткәрү сроклары**

7.1. Бәйгегә гаризалар 2021 елның 31 декабренә (23.59 сәгатькә) кадәр кабул ителә.

7.2. Бәйгенең җиңүчеләре 2022 елның 15 гыйнварында игълан ителә.

7.3. Җиңүчеләр исемлеге Интернет челтәрендә https://matbugat.ru/ адресы буенча урнашкан Оештыручының рәсми сайтында һәм «Блогер.Татар» бәйгесенең https://www.bloger.tatar сайтында игълан ителә.

**8. Бәйгене оештыручының бурычлары**:

- Эшләрне кабул итү;

- Эшләрнең бәйге таләпләренә туры килүен тикшерү;

- Бәйгенең канун таләпләренә туры килүен тәэмин итү;

- Жюри туплау һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;

- Бәйгенең документациясен алып бару;

- Массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәдә булу;

- Җиңүчеләрне бүләкләү.

**9. Йомгаклау нигезләмәләре**

9.1. Әлеге Нигезләмәдә күрсәтелмәгән мәсьәләләр, Комиссия рәисе белән килештерелеп, Оештыручы тарафыннан хәл ителә.

9.2. Бәйгенең Интернетта рәсми бите: Bloger.tatar